**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 ноябрь № 882

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт архивлары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 476 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт архивлары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 476 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 910 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) эшнең катлаулылыгы, киеренкелеге өчен һәм хезмәттәге югары казанышлар өчен айлык өстәмә түләүне – вазыйфаи окладның 150 процентыннан алып 200 процентына кадәр күләмдә;»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) эшнең катлаулылыгы, киеренкелеге, хезмәттәге югары казанышлар өчен айлык өстәмә түләүне һәм дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык процент өстәмәсен – 22 вазыйфаи оклад күләмендә;».

2. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\882.docx